ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге закон Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә региональ салымнар буенча недоимка, шушы салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгели.

2 статья. **Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр**

2017 елның 1 гыйнварына региональ салымнар буенча недоимка, шулай ук әлеге салымнар буенча түләнүгә ышанычсызлыкны тану турында карар кабул ителү датасына саналган, аерым салым түләүчеләргә исәпләнелгән, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләнү мөмкин булмаган пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсыз дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

2) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган региональ салымнар буенча оешмаларда яисә индивидуаль эшкуарларда исәпләнелә торган недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу;

3) салым исәбенә куелган һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында үзләренә карата мәгълүмат булмаган оешмаларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

4) “Башкару эшчәнлеге турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлеге тәмамлану турында башкаручы суд приставының карары чыгарылуга бәйле рәвештә салым органнары тарафыннан түләтү мөмкин булмаса һәм, әгәр недоимка һәм (яисә) пенялар һәм штрафлар буенча бурычы барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт үтсә, бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда тормаган физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

5) оешмаларның пенялар исәпләнә торган недоимкасы булмаганда, әлеге недоимканы түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән пенялар буенча бурычы булу.

3 статья. **Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар**

Әлеге Закон кушымтасы нигезендә региональ салымнар буенча недоимка, шушы салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеген расларга.

4 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 19 июль
№ 54-ТРЗ

"Региональ салымнар буенча недоимка,
пенялар һәм штрафлар буенча бурыч
түләнүгә ышанычсызлыкны тануга
өстәмә нигезләр билгеләү турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеге**

1. Әлеге Законның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

2) физик затның үлү фактын физик затларның граждан хәле актларын теркәүче орган тарафыннан теркәү турында Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясындагы 3 пункты нигезендә салым органына кергән белешмәләр;

3) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы).

3. Әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) оешманы исәпкә алу урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) юридик зат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында мәгълүматның булмавы хакында теркәүче орган белешмәсе.

4. Әлеге Законның 2 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) физик затның яшәү урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) "Башкару эшчәнлеге турында" 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча түләтүчегә башкару документы кире кайтарылганда

башкару эшчәнлегенең тәмамлануы турында башкаручы суд приставы карарының күчермәсе;

3) физик затның бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда тормавы турында салым органы белешмәсе.

5. Әлеге Законның 2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, – оешманы исәпкә алу урыны буенча салым органының пенялар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе.